ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘТНӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ОЛЫ ӘТНӘ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
БОЛЬШЕАТНИНСКОГО СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ АТНИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

422750 Республика Татарстан Атнинский район с.Б.Атня Тел.2-15-68

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

№ 20 17 август 2022 ел

**Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районының «Олы Әтнәавыл җирлеге» муниципаль берәмлеге исеменнән, башкару җитештерү циклының озынлыгы бюджет йөкләмәләренең расланган лимитларының гамәлдә булу срогыннан артып киткән эшләр башкару, хезмәтләр күрсәтү предметы булып торган муниципаль контрактларны төзү турында карарлар кабул итү тәртибен раслау хакында**

Россия Федерациясе Бюджет кодексының 72 статьясындагы 3 пуктынын өченче абзацы, Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районының Олы Әтнә авыл җирлеге уставы нигезендә, Олы Әтнәавыл җирлеге башкарма комитеты карар бирә:

1. «Олы Әтнә авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге исеменнән, башкару җитештерү циклының озынлыгы бюджет йөкләмәләренең расланган лимитларының гамәлдә булу срогыннан артып киткән эшләр башкару, хезмәтләр күрсәтү предметы булып торган муниципаль контрактларны төзү турында карарлар кабул итү тәртибен расларга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районының рәсми сайтында интернет челтәрендә http://atnya.tatarstan.ru адресы буенча урнаштырырга һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының http://pravo.tatarstan.ru рәсми порталында бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Олы Әтнә авыл җирлеге
башкарма комитеты җитәкчесе: Л.А.Самигуллин

Әтнә муниципаль районы Олы
Әтнә авыл җирлеге башкарма
комитетының 2022 ел 17 август
№ 20 карарына 1 нче кушымта

**Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районының «Олы Әтнә авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге исеменнән, башкару җитештерү циклының озынлыгы бюджет йөкләмәләренең расланган лимитларының гамәлдә булу срогыннан артып киткән эшләр башкару, хезмәтләр күрсәтү предметы булып торган муниципаль контрактларны төзү турында карарлар кабул итү тәртибен**

1. Әлеге Тәртип Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы «Олы Әтнә авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге башкару җитештерү циклының озынлыгы бюджет йөкләмәләренең расланган лимитларының гамәлдә булу срогыннан артып киткән дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен эшләр башкару, хезмәтләр күрсәтү предметы булган муниципаль контрактларны төзү турында карарлар кабул итү кагыйдәләрен билгели,

2. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районының «Олы Әтнә авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге ихтыяҗлары өчен башкару җитештерү циклының озынлыгы бюджет йөкләмәләренең расланган лимитларының гамәлдә булу срогыннан артып киткән (алга таба - озак сроклы муниципаль контрактлар) эшләр башкаруга, хезмәтләр күрсәтүгә муниципаль контрактлар,

Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районының Олы Әтнә авыл җирлеге Советы карары белән каралган вакытка һәм чикләргә түбәндәгеләрне билгели торган чаралар чикләрендә төзелергә мөмкин:

- эшләр башкаруның, хезмәтләр күрсәтүнең планлаштырыла торган нәтиҗәләре;

- эшләр, хезмәтләр составы тасвирламасы;

- подрядчыларны, башкаручыларны билгеләү өчен кирәкле срокларны исәпкә алып, эшләрне башкаруның, хезмәтләр күрсәтүнең иң чик срогы;
- елларга бүленгән озак сроклы муниципаль контракт өчен түләүгә акчаларның иң чик күләме.

3. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районының Олы Әтнә авыл җирлегенең әлеге Тәртиптә каралган муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен муниципаль контракт төзү турындагы карары индивидуаль характерда түбәндәге тәртиптә кабул ителә:

а) Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районының Олы Әтнә авыл җирлеге Советы карары проекты һәм аңа аңлатма язуы билгеләнгән тәртиптә районның финанс-бюджет палатасына килештерүгә җибәрелә;

б) Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Олы Әтнә авыл җирлеге Советы карарын һәм аңа аңлатма язуын алган көннән алып 15 көннән дә артмаган срокта районның финанс-бюджет палатасы күрсәтелгән проектны түбәндәге шартларны үтәгәндә килештерә:

- агымдагы финанс елында һәм план чорында муниципаль контракт өчен түләүгә күздә тотыла торган акчаларның иң чик күләмен тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районының «Олы Әтнә авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге бюджеты турындагы карары белән каралган бюджет ассигнованиеләре күләменнән арттырмау;

- план чорыннан читтә муниципаль контракт өчен түләүгә күздә тотыла торган акчаларның еллык иң чик күләмен план чоры чикләрендә (агымдагы финанс елында) күрсәтелгән муниципаль контракт өчен түләүгә акчаларның максималь еллык күләменнән арттырмау;

в) Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районының Олы Әтнә авыл җирлеге Советының Финанс-бюджет палатасы белән килештерелгән карары проекты билгеләнгән тәртиптә раслау өчен аны эшләгән органга тапшырыла.